**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Күтәмә авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлеге составына керүче Күтәмә авылы торак пунктында

**27.10.2023 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлегенең Күтәмә торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2024 елда Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 800 сум күләмендә үзара салым кертергә, I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операцияләрендә булган гражданнардан тыш»

2. Алынган чараларны җибәрергә:

- Күтәмә торак пунктында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга;

- Күтәмә торак пунктында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләргә түләү, запас частьләр сатып алу, асылмалы һәм тагылма җиһазлар сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнарына;

- җәмәгать пространстволарын төзекләндерү, авыл җирлеге урамнарын җәй көнне карап тоту (триммерлар, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар алу

- Күтәмә авыл җирлегендә урам-юл челтәрен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу: вак таш сатып алу.

- вак таш сатып алуга 125000,00 сумлык 2022 елның үзара салым чаралары калдыкларын куллану.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче**
**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Күтәмә авыл җирлеге башлыгы** **Н.Г.Сабиров**